ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясе дәүләт теле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 468229-8 номерлы федераль закон проекты турында (гавами киңлектә Россия Федерациясе дәүләт теле буларак рус телен куллануны тәэмин итү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе дәүләт теле буларак рус телен яклауны һәм гавами киңлектә чит ил сүзләре (алынма сүзләр) куллануны чикләүгә юнәлдерелгән «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 468229-8 номерлы федераль закон проектын (гавами киңлектә Россия Федерациясе дәүләт теле буларак рус телен куллануны тәэмин итү хакында) (алга таба – 468229-8 номерлы федераль закон проекты) хупларга.

2. Әлеге закон проектында күрсәтелгән өлкәләрдә Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрен һәм Россия Федерациясе халыклары телләрен куллану мөмкинлеген өстәп, 468229-8 номерлы федераль закон проекты текстын үзгәртүне тәкъдим итәргә.

3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында 468229-8 номерлы федераль закон проектын караганда әлеге карарның 2 пунктында бәян ителгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тәкъдимен, шул исәптән беренче укылышта кабул ителгәннән соң тиешле төзәтмәләр кертү юлы белән, күрсәтүне Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты А.З. Фәрраховка йөкләргә.

4. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 ноябре
№ 2257-VI ДС